Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

21 октябрь, 2020 ел № 9

Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Күн авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 141 номерлы Күн авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Күн авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1.Кызыл Яшьләр авылында. 2020 елның 3 ноябрендә 8.00 сәгатьтә Колхоз урамындагы 9 нчы йорт янында гражданнар җыенын үткәрергә

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2021 елда Күн авыл жирлеге Кызыл Яшьләр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы студентларын, 90 яшьтән өлкәнрәк кешеләрне бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- су белән тәэмин итү системасын урнаштыру

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Әлбәдән авылында. Гражданнар җыенын 2020 елның 3 ноябрендә 10.00 сәгать Күл буе урамы, 25а йорт адресы буенча урнашкан ФАП бинасы янында үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2021 елда Әлбәдән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм

жирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау;

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.3. Кун авылында. Халык җыенын дүрт этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2020 елның 5 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Совет урамы, 61а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Яңа, Урман, Мәктәп урамнары, Кави Шакиров урамының 1-25 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2020 елның 9 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Совет урамы, 61а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Кави Шакиров урамының 26-52 йортлары, Совет урамының 1-64 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының өченче этабы 2020 елның 11 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Совет урамы, 61а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Совет урамының 65-117 йортлары, М.Конов урамы буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының дүртенче этабы 2020 елның 13 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Совет урамы, 61а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Комсомол, Тукай, Пионер урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

«Сез, 2021 елда Кун торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы студентларын, 90 яшьтән өлкәнрәк кешеләрне бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм жирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау;

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Кун авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Кун авыл җирлеге башлыгы

СОВЕТ КОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "КОНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ" ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИНН 1633000842

Р.Г. Баһауов